**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Коморгузинского сельского поселения Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана, зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл жирлеге Советы**
422758, Комыргужа авылы, Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
«29» октябрь 2025 ел. № 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге Комыргужа торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2025 елның 07 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлегенең Комыргужа торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге Комыргужа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге башкарма комитеты;
- халык җыенын үткәрү вакыты 07 ноябрь 2025 ел 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Комыргужа авылы, Пионер урамы, 22 нче йорт,Комыргужа мәдәният йорты залы;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргужа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт;
- сайлау хокукына ия булган Комыргужа торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Комыргуҗа торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2."Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Комыргуҗа авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Комыргуҗа авылында үлән чабу; Комыргуҗа авылындагы паркта газон чабу).

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен изелгән таш сатып алу (эш һәм хезмәт өчен түләү); урам юлларын чистарту; кардан Комыргуҗа авылы.

3) Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны яхшырту (Комыргуҗа авылы зираты территориясен чистарту (үлән чабу)).

4) Урамдагы ачык яктырту челтәрләрен, трансформаторны һәм алар өчен бүтән подстанцияләрне, участокларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен таратылган башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту техникасы (лампаларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Шарипов

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1610000733 ОГРН 1021606156142